КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 10 декабрь г.Казань № 1103

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында лизинг рәвешендәге инвестицияләрне үстерү чаралары турында» 2006 ел, 28 февраль, 79 нчы карары белән расланган «Татлизинг» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе уставына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында лизинг рәвешендәге инвестицияләрне үстерү чаралары турында» 2006 ел, 28 февраль, 79 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 29 декабрь, 1088 нче; 2013 ел, 24 июнь, 437 нче; 2015 ел, 3 июнь, 405 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1027 нче; 2017 ел, 18 март, 153 нче; 2018 ел, 2 октябрь, 895 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татлизинг» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе уставына, аңа түбәндәге эчтәлекле 8 бүлек өстәп, үзгәреш кертергә:

«8. Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу

8.1. Мәнфәгатьләр каршылыгы дигәндә Предприятие хезмәткәренең шәхси мәнфәгате (турыдан туры яки читләтеп) аның тарафыннан хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәүгә йогынты ясаган яки ясый алган һәм ул чакта Предприятие хезмәткәренең шәхси мәнфәгате һәм ул хезмәткәре булган Предприятиенең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында Предприятиенең мөлкәтенә һәм (яки) эшлекле репутациясенә зарар китерергә сәләтле хәл аңлашыла.

Предприятие хезмәткәренең хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәүгә йогынты ясаган яки ясый алган шәхси мәнфәгате дигәндә хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле Предприятие хезмәткәре тарафыннан үзе өчен һәм (яки) аның белән

якын туганлыкта яки үги туганлыкта торучы затлар (әти-әнисе, ире һәм хатыны, балалары, ир туганнары, кыз туганнары, шулай ук ир һәм хатынының ир туганнары, кыз туганнары, әти-әнисе, балалары һәм балаларының ире һәм хатыны), үзе өчен һәм аның белән якын туганлыкта яки үги туганлыкта торучы, мөлкәти, корпоратив яки бүтән якын мөнәсәбәтләрдә торучы граждан яки оешмалар өчен акча, кыйммәтле әйберләр, бүтән мөлкәт, шул исәптән мөлкәт хокуклары, мөлкәт характерындагы хезмәт күрсәтүләр, башкарылган эшләр нәтиҗәләре яки ниндидер файда (өстенлекләр) рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аңлашыла.

8.2. Предприятие җитәкчесе вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү мөмкинлеге булган шәхси мәнфәгате барлыкка килү турында эш бирүчегә (гамәлгә куючыга) хәбәр итәргә тиеш.

8.3. Предприяте хезмәткәре вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү мөмкинлеге булган шәхси мәнфәгате барлыкка килү турында Предприятие җитәкчесенә хәбәр итәргә тиеш. Предприятие җитәкчесенә хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдәге мәгълүматлар исемлеге, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе Предприятие җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин